Бүгенге санда:

Шимбә өмәсендә шәһәрдән 173 кубометр чүп чыгарылган. 2 бит

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе
15
апрель
2015 ел

№ 27 (10556)

16 апрельгә һава торышы: алмашынучан болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көньяктан, 4-6 м/с; температура көндез +10°С, төнлә +7°С

Ашламаның дымга төшүе яхшы

Автор фотосы

ОЛЕГ ЧЕРНОВ БЕЛӘН АЛЕКСАНДР ЕРЕМЕЕВ БЫЕЛ ДА БАСУГА БЕРЕНЧЕЛӘРДӘН БУЛЫП ЧЫКТЫЛАР.

Район хуҗалыклары язгы кыр эшләренә керештеләр. Хуҗалыклар нигездә уҗым культураларын һәм күпьеллыкларны өстәмә тукландыру белән мәшгуль.

"Сөләйманов Ә.И" крестьян-фермер хуҗалыгының Илюткинодан ерак түгел урнашкан уҗым бодае басуында иртәнге 5тән җанлылык хөкем сөрә. Шөкер, һава торышы көйле тора, басу юллары да кипшенергә өлгергән инде. Шуңа да ашлама китерү белән проблема юк диярлек. Дөрес, басу юеш әле. Тик Сөләймановлыларны бу куркытмый. Чөнки ашламаны "Туман" дип аталган үзйөрешле җайланмалар белән тараталар. "Туман"ның зур тәгәрмәчләре исә агрегатка дымлы урыннарга керергә мөмкинлек бирә, кар астыннан яңа гына чыккан уҗымнарга да зыян килми.

- 800ләп гектарда уҗымнарны тукландырдык. Ашлама кертер өчен менә дигән вакыт инде хәзер, - ди хуҗалыкның Фома бүлекчәсе агрономы Рамил Нямаев. – Чөнки җирдә дым бар, туфрак кибеп китсә, ашлама кертүнең файдасы аз булачак.

"Туман"нарны ел да шулай язгы кыр эшләре вакытына махсус кайтаралар икән хуҗалыкта. Чөнки агрегатларның хезмәт җитештерүчәнлеге югары. Әнә, бер шундый агрегат белән көн дәвамында 300ләп гектар уҗымны өстәмә тукландырырга өлгерәләр. Сәгатенә 30–33 км. тизлек белән йөреп, бункерындагы ашламаны 20 минут дигәндә таратып чыга әлеге агрегат. Шуңа да ашлама төяүчеләр Александр Еремеев белән Виталий Туймешевка бер дә тик торырга туры килми. Ашлама төялгән олы капчыкларны күтәрткечкә эләктереп, "Туман"нарның сыешлыгына бушаталар алар. Ә менә ашламаны басуга Олег Чернов белән Евгений Паруков китереп өлгертеп тора. Барысы да тәҗрибәле хезмәтчәннәр, чәчүдә дә беренче генә катнашулары түгел, яхшы уңыш алу өчен кыр эшләрен иртә яздан вакытында башкарырга кирәклеген яхшы беләләр.

Бу басуда эшләрне тәмамлауга ашлама кертүчеләр бригадасы янәшәдәге кырга күченәчәк. Хуҗалык агрономының сүзләренә караганда, уҗымнар гына да 5000ләп гектарда быел хуҗалыкта. Чәчүлек җирләре дә узган елгыга караганда артыграк буласы. Димәк, хуҗалык игенчеләренә быел тагы да тырышыбрак эшләргә туры киләчәк.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

Җиңү календаре

24

БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ – 9 МАЙГА КАДӘР ШУЛКАДӘР ВАКЫТ КАЛДЫ

1945 елның 16 мартыннан 15 апреленәчә 2 һәм 3нче Украина фронтлары гаскәрләре 1нче Болгария армиясе ярдәмендә Венага таба һөҗүм итү операциясе үткәрә. Нәтиҗәдә, Венгрия һәм Австриянең көнчыгыш өлеше дошманнан азат ителә.

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

Абзац-информ

ӘЗЕРЛЕК КОНТРОЛЬДӘ

Кичә район башлыгы Равил Кузюров Казанның "Новые Горизонты" фирмасы вәкилләре, район-шәһәр башкарма комитетлары җитәкчеләре белән берлектә үзәк мәйданның Җиңүнең 70 еллыгына әзерлеген карап чыкты. Ул эшләрнең төгәлләнү этабында исәпкә алынырга тиешле рекомендацияләрен бирде, үзәк мәйдан 5нче майга тулысынча әзер булырга тиеш, диде.Шул ук көнне анда фонтанны эшләтеп җибәрү дә планлаштырыла.

ТОРАК ӨЧЕН ХИСАП ТОТАЛАР

Бу көннәрдә районның ятим балаларына дәүләт программасы нигезендә бирелгән торак фондын тикшерү бара. Район башкарма комитеты, опека һәм попечительлек бүлеге,торак сәясәте һәм ТСЖ службалары көн саен адреслар буенча йөриләр. Төп игътибар фатирның сакланышына, үзвакытында коммуналь түләүләрне башкаруга һәм башка аспектларга юнәлдерелә.

БРАКОНЬЕРЛАР БАЛЫКСЫЗ КАЛАЧАК

Район балыкчыларының тиеш булмаган вакытта ау оештыруларының 2 очрагы теркәлгән. Кагыйдә бозуның бер материалы судка юлланган. Әлеге браконьерлар бу сезонда балык тотуга рөхсәт кәгазьсез дә калырга мөмкиннәр. 25 апрельдән исә "Уылдык чәчү" операциясе старт алачак.

КӨН КАДАГЫНДА

Машина тоту кыйммәтләнә бара

Эш атнасы машина хуҗалары өчен бик үк сөенечле булмаган яңалык белән башланды: 12 апрельдән ОСАГО – мәҗбүри автогражданлык җаваплылыгын иминиятләштерү буенча база тарифы 40 процентка күтәрелде. Моңа кадәр 101-120 ат көчле машина хуҗалары полис өчен 3-4 мең сум түләгән булсалар, хәзер 8–9 мең сум акчаларын чыгарып салырга тиеш булачак.

Артулар соңгысы булмаска охшаган, диләр иминиятчеләр, чөнки иминиятләштерүдән кергән акчалар клиентларга ук китеп бетә, ди. Бәяләр артуны зыян күрүчеләр өчен түләнүче лимитлар, запас частьларга бәяләр арту һәм башкалар белән бәйлиләр. Бәя артуны 2014 елның октябренә кадәр полислар алган машина йөртүчеләр тоячак, диләр белгечләр. Алар өчен ОСАГО икеләтә артачак, ди.

– Хатын-кыз гаебе белән килеп чыккан бер транспорт һәлакәтендә өч яхшы чит ил машинасы зыян күрде, - ди шәһәрдәге иминият компаниясе хезмәткәре бер очракка тукталып. – Зыян күргән өч машина өчен 400әр мең сум түләү каралган. Нәтиҗәдә, иминият компаниясенә 1 миллион 200 мең сум акча чыгарып саласы булачак. Ә әлеге хатын-кыз ОСАГО өчен 4 мең сумнар тирәсе түләгән булган. Менә шуннан санагыз, шундый сумманы түләү өчен күпме машина йөртүчене иминиятләштерергә кирәк булачак. Машина йөртүчеләрнең тормышларын "көчләп" иминиятләштерү дә шул чыгымнарны каплау өчен эшләнә инде. Әмма ни генә булмасын, закон гамәлгә кергән.

ОСАГО тарифларының артуларын нурлатлылар да тыныч кына кабул итә алмый.

– ОСАГОны 2003 елдан бирле түләп барам, - ди бер танышым. – Шул чорда бер генә тапкыр да юл-транспорт һәлакәте китереп чыгарганым юк. Аңлавымча, минем ОСАГО түләүләрем "башсыз автоузышчылар" һәм кемнеңдер бизнесы өчен тотыла.

– Өч ел инде ОСАГОсыз йөрим, - ди Ринат. –ОСАГО өчен 4000 сум түләгәнче, 500 сум штраф түлим мин. Бәяләр күтәрелгәч, күп кеше полислар сатып алмаячак. Иминиятчеләрнең керемнәре тагын төшәчәк.

Әмма юл һәлакәтеннән берәү дә гарантияләнмәгән, һәм иминиятләштерүдән баш тартуның да бик кыйммәткә төшүе ихтималын онытмыйк.

ЮХИДИнең теркәү бүлегендә хәбәр итүләренчә, ОСАГО бәяләре күтәрелү машина сатып алучылар санына әлегә йогынты ясамаган.

Зилия ӘКСАНОВА

ИГЪТИБАР!

ОСАГО килешүе күпмедер чикләүләрне үтәгән очракта, аерым алганда, автомобиль белән бары тик аек килеш идарә иткәндә генә гражданнарның милек җаваплылыгын яклый.

КӨН КАДАГЫНДА

Президентка сорау

Иртәгә, 16 апрельдә РФ Президенты Владимир Путин халык белән традицион туры линия уздыра.

Сораулар кабул итү 9 апрельдән үк башланган иде инде. Аларны бүген һәм иртәгә дә юллап булачак әле. **16 апрельдә туры линия тәмамланганчыга кадәр стационар яки мобиль телефоннардан бушлай 8-800-200-40-40 номеры буенча шалтыратып яки смс җибәреп, яисә 040-40ка видеосорау юллап Владимир Путинга мөрәҗәгать итәргә мөмкин.**

Ел саен Президентка миллионлаган сораулар юллана. Мондый туры линияләрдән россиялеләр уңышлы файдалана һәм аңа ышана. Ә җирле масштабта бу функцияне Д.Медведевның "Бердәм Россия" партиясе каршындагы җәмәгать кабул итүе башкара. Бүлекчәнең башкарма комитеты җитәкчесе Ралия Ханиева әйтүенчә, аларда җирле депутатлар да, ТР Дәүсоветы депутатлары Илгиз Салихов һәм Рәис Сөләйманов та, РФ Дәүләт Думасы депутаты Фатих Сибагатуллин да кабул итүләр алып бара. Нурлатлыларның проблемаларына төрле дәрәҗә депутатларның игътибары нәтиҗәле карарлар табарга булыша.

– Бездә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү көннәре дә бик популяр, аларда егермеләп кеше профессиональ юристлар: адвокатлар, прокуратура хезмәткәрләре, нотариусларның җавапларын алалар, – ди Ралия Ханиева.

Валентина ВАФИНА

САНИТАР ИКЕАЙЛЫК

Беренче гомумшәһәр өмәсе үтте

Шимбә көнне каты көнкүреш калдыклары полигоны 173 кубометр чүп кабул итте. Предприятие, оешмалар, мәктәп, балалар бакчалары коллективлары катнашында үткән гомумшәһәр өмәсенең нәтиҗәсе шундый.

УТТның 80нән артык хезмәткәре предприятиеләре янындагы һәм үзләренә беркетелгән территорияләрдә генә түгел, идарәнең трактор колоннасы урнашкан Андреевкада да тәртип салдылар. Тимер юлчылар микрорайонында "Промочистка" хезмәткәрләре экологик эш җәелдерде. Үзләренә беркетелгән Куйбышев урамыннан тыш, алар ветераннар яшәүче Кузнецов урамын да тәртипкә китерделәр: иске агачларны кистеләр һәм шунда ук чыгара да бардылар.

- Шунда яшәүчеләр чыкса, һәрчак чиста булыр иде дә бит, - ди биредә яшәүче һәм өмәгә кушылган Зәкия Җиһаншина.

"Амальстрой+" хезмәткәрләре җомга көнне Лесосклад урамында, ә шимбәдә үзләренең Совет урамында урнашкан конторалары янында эшләделәр, хәтта коймаларын да щетка белән юып тәртипкә китерделәр.

- Безгә дә күңелле, узып баручыларга да, - дип уртаклашты механик Ринат Рәхмәтуллин.

Җылылык челтәрләре хезмәткәрләре дә өмәгә ике көн рәттән чыктылар. Нәтиҗәсе дә матур: күпфункцияле үзәк белән җылылык челтәрләренең административ бинасы арасындагы сквер чистарып, янбакчалары матураеп калды, корыган агачларны җыйдылар, баганаларны акшарладылар. Аларның күршеләре - Пенсия фонды идарәсе коллективы да эштән читтә калмады: кар тараттылар, кыштан җыелган чүпне җыештырдылар. НУАД, картлар һәм инвалидлар интернат-йорты, мәгариф учреждениеләре, кибетләр, "Нурлатнефть" спорткомплексы, ЛУТР, элеватор, ТСЖлар һәм башка оешмалар коллективлары да аерылып торды. Шәһәр башкарма комитетыннан әйтүләренчә, чүпне вакытында чыгару өчен коммуналь служба өстәмә ике МТЗ тракторы, 1 чүп ташыгыч, 1 бункеровоз чыгарган. Моннан тыш, өмә кысаларында "Төзекләндерү биш" "Ивушка" балалар бакчасы янында юл билгеләре урнаштырган, 6 контейнер мәйданчыгын ремонтлаган. Күпләр болар әле эшнең башы гына булуын билгеләп үттеләр, алдагы этап буяу һәм агарту эшләре булачак. Әмма, кызганычка каршы, шәһәрдә кул тимәгән почмаклар да күп әле. Икеайлык барышында алар да игътибарсыз калмас, дип ышанасы килә.

Сирень СӘМӘРХАНОВА,
автор фотолары

УТТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ӨМӘГӘ БЕРЕНЧЕЛӘРДӘН БУЛЫП ЧЫГА

ЧҮП ТҮГҮ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ ТЕХНИКА БҮЛЕП БИРЕЛДЕ

ҖЫЛЫЛЫК ЧЕЛТӘРЛӘРЕ КОЛЛЕКТИВЫ ЧҮП ТӘ ТҮКТЕ, АГАРТТЫ ДА....

"ПРОМОЧИСТКА" БАРЫНА ДА ӨЛГЕРДЕ: ҮЗ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕН ДӘ ЧИСТАРТТЫ, ВЕТЕРАННАРГА ДА БУЛЫШТЫ

Төзекләндерү кагыйдәләрен бозалармы? Административ комиссиягә шалтыратыгыз: 2-06-15.

ХӘБӘРЛӘР

ЯҢА УКУ ЕЛЫННАН - ЯҢА ФОРМА

Яңа уку елыннан мәктәп укучылары кызыл шакмаклы "шотландка" итәкләр һәм сырлы кара костюмнар киеп йөрмәячәк. Нурлат шәһәре һәм районының күпчелек мәктәпләре укучылары өчен 5 ел мәҗбүри булган әлеге бердәм мәктәп формасын Ульян шәһәренең бер фабрикасында тегелгән яңа фасондагы, соры төстәге костюмнар алмаштырачак. Бу көннәрдә мәктәпләрдә ата-аналарны әлеге фабрика тәкъдим иткән яңа формалар һәм прайс-листлар белән таныштыралар.

- Яңа формага күчү этаплап алып барылачак. Һичшиксез, быелдан бу формаг күчәсез, дип мәҗбүр итүләр булмаячак - ди район мәгариф идарәсе начальнигы Линар Маняпов. – Әлбәттә, быел 1нче сыйныфлар барысы да бердәм форма сатып алачак. Яңа форма элеккегесеннән кырысрак, классик стильдә булуы белән аерылып тора. Ул ГОСТ таләпләренә туры килә, бәяләре дә чамалы.

Яңа форма кыз балалары булган ата-аналарның күңеленә аеруча хуш килдер, мөгаен. Чөнки кызлар өчен форма костюм, жилет, итәк белән бергә классик чалбарны да үз эченә ала.

ИҢ КҮП БАЛЛ "СӨЛӘЙМАНОВ"ЛЫЛАРДА

Узган атнада район хуҗалыкларының язгы чәчүгә әзерлеге агросәнәгать комплексы оешмалары арасында оештырылган республика конкурсы кысаларында тикшерелде. Составында ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының инженер-техник тәэмин ителеш бүлеге белгече Руслан Мөбарәкҗанов, районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Гостехнадзор, Россельхознадзор белгечләре булган комиссия иң яхшы әзерлек "Сөләйманов ФХсында дип тапты. Сөләймановлылар 40 мөмкинлектән 39 балл туплаган. Икенче урында – "Южная" агрофирмасы, аның әзерлеге 38 балл белән бәяләнгән. Өченчедә - "АгроРазвитие"леләр. Гомумән, район буенча хуҗалыкларның язгы чәчүгә әзерлеге уңай бәяләнде, дип билгеләделәр үтәләр комиссия әгъзалары.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

МӘДӘНИ КӨНДӘЛЕКЛӘРНЕ ТИКШЕРЕ

Бу көннәрдә балалар китапханәсе "Беренче сыйныф укучысының мәдәни көндәлеге" республика проекты буенча эш дәвам итә.

Шәһәрнең барлык мәктәпләренең 1 нче сыйныф укучылары белән очрашулар үтте. Аларга көндәлекләрне оформить итү, методик ярдәм күрсәтелә, төрле конкурслар буенча консультацияләр бирелә. Конкурснының район этабы 1 майга кадәр дәвам итәчәк. Аның нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр билгеләнәчәк. Өч иң яхшы көндәлек һәм иң яхшы мәдәни әти-әни республика этабында төп приз өчен көч сынашачак.

Маргарита Л...

БИКҮЛЕ ТЕАТРЫ ИСЕМЕН РАСЛА...

Бикүле халык театры Әлмәттә узган "Ил йорт" халык театрларының XV төбәк конкурс-фестивалендә чыгыш ясап кайтты. Фестивальдә нурлатлылар әлмәтле... Наил Гаетбайның "Әстәгъфирулла" спектаклен тәкъдим иттеләр. Жюри үзешчән артистлар – Тәнзилә Әнлетдинова, Минсәрия Мостафин, Илшат Гайсин, Кадрия Өндәржанова, Нәфисә Хәсәнованың уен...рын уңай бәяләп, театрның халык исемен раслаган һәм коллективны Диплом белән бүләкләгән.

Зилия ӘКСА...

"ДУСЛЫК"КА ЯЗЫЛУ БАРА

"ДУСЛЫК" ("ДРУЖБА", "ТУСЛАХ") район газетасына 2015 елның II яртыеллыгына язылу бара.

Сезне почтада һәм редакциянең реклама бүлегендә көтәләр.

ВАКЫТ. ВАКЫЙГА. РЕКЛАМА

ИМИНЛЕК

Һәркем үзеннән башларга тиеш

Узган атнада республика Хөкүмәт комиссиясенең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча видеоконференция режимында үткән утырышында, юл билгеләре, разметкаларга кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып шөгыльләнер чак җитүе турында сөйләшенде. Утырышны ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Шамил Гаффаров алып барды.

Нурлат районында узган ел белән чагыштырганда юл-транспорт һәлакәтләре азайса да, бу мәсьәлә актуаль булып кала әле.

– Район юлларына өстәмә рәвештә билгеләр куябыз, вакыты җиткәч, ясалма тигезсезлекләр дә ясалачак, – диде район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин. – Юл хәрәкәте буенча күпчелек мәсьәләләрне апрель азагына таба хәл итә башлаячакбыз. Мисал өчен, 9нчы мәктәп һәм гимназия янында муниципаль бюджет средстволарына машина тукталышлары ясау планлаштырыла.

Тулаем алганда, җирле бюджет исәбенә 3800 мең сумга җәяүләләр кичүләре, машина тукталышлары гына түгел, юл билгеләре, разметкалар, ясалма тигезсезлекләр ясау да каралган. Шулай ук федераль максатчан программа да бар, аның исәбенә дә бу юнәлештә эшләр башкарылачак. Мәсәлән, 4 белем бирү учреждениесе – "Тиенкәй", "Чык тамчысы" бакчалары, 8нче һәм 1нче мәктәпләр яннарында җәяүләләр кичүләре пәйда булачак, ә соңгысы янына светофор кую да планлаштырыла.

Республика юлларында термопластик разметкалар барлыкка килде. Бу уңайдан НУАД начальнигы Фидаил Садыйков аны бары тик кайнар асфальтка гына төшереп булуын әйтте. Мондый яңалык бездә Каравыл Тавы, Мамык, Киекледә җәяүләләр кичүе буларак пәйда булачак, диде.

Видеоконференциядән соң сөйләшүне шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин дәвам итте. Ул нурлатлылардан сәүдә объектлары урнашкан Кооператив урамындагы хәрәкәткә кагылышлы сораулар керә, диде, алар урамның бу өлешен, элеккеге кебек, ябарга тәкъдим итәләр икән. Шулай ук К.Маркс урамының тулылыгын да билгеләп үтте.

Монысы проблеманың бер ягы булса, икенчесе – машина йөртүчеләрнең тәртипсезлеге. Нурлат районы ЮХИДИ начальнигы Рөстәм Гарипов әйтүенчә, бу уңайдан өш очракта кагыйдәне җитәкчеләр боза икән. Ул бу темага кагылышлы башка мәсьәләләргә дә тукталды.

– Районда бер квартал эчендә 3 юл-транспорт һәлакәте булды, зыян күрүчеләр бар, шөкер, һәлак булучылар юк, – диде ЮХИДИ җитәкчесе. – Ситуацияне үзгәртер өчен тәртипне иң элек үзебездән башларга кирәк, машина йөртүчеләрнең үзаңын үзгәртергә, бала чактан ук юлда имин йөрү кагыйдәләрен сеңдерергә.

Фиксацияләү системасы уңаеннан, ЮХИДИ начальнигы 2014 елда һәм 2015нең башында районда аларның унлап урынга куелганлыгын, хәзер исә 20гә җиткәнлеген әйтте. Аларның урыннарын даими алыштырып торалар, кагыйдә бозучылар ачыклана. Ә менә "Халык инспекторы" системасы буенча нурлатлылар актив түгел, диде Рөстәм Гарипов. Ә бит бу юллардагы куркынычсызлык проблемаларын хәл итүдә булышыр иде.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

Автор фотосы

СПОРТ. СӘЛАМӘТЛЕК

ГТОның өстенлекләре зур

Узган җомга көнне шәһәрнең үзәк паркы зур спорт мәйданчыгына әверелде: биредә нурлатлылар массакүләм рәвештә ГТО нормалары тапшырдылар.

Бүгенге чарада шәһәрнең оешма-предприятиеләре хезмәткәрләре, район, шәһәр башкарма комитетлары, Советлары белгечләре катнаша, – диде яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Әнәс Нәбиуллин. Шул рәвешле, 200 нурлатлы урыннан сикерү, йөгерү, граната ыргыту, мылтыктан ату кебек унлап спорт төрендә үз көчләрен сынап карады.

Бу көнне спорт чарасында катнашучылар фикеренчә, ГТОны шулай массакүләм тапшыру коллективтагы дуслыкны нык ныгыта, көндәшлек шартларында югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Мисал өчен, район башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе Владимир Борисов 54 яшьтә дә егерме отжимание ясап, үзенең яхшы физик формада икәнлеген күрсәтте.

– Элек, башка оешмаларда эшләгәндә дә спорт белән дус булдым, – ди ул. – Әлбәттә, спортны яраткан кешене моңа мәҗбүр итүнең кирәге юк аны сы. Әмма ГТО нормаларын кайтару бик яхшы нәрсә, ул үз-үзеңне тикшереп карау, алга таба тагы да яхшырак нәтиҗәләргә ирешү өчен бер дигән стимул.

Хәер, ГТО нормаларын тапшыруда илебез Хөкүмәте өстәмә мотивация булдыру өчен дә кайбер карарларын чыгарды. Мисал өчен, ГТО нормаларын уңышлы тапшыручыларның ВУЗга укырга кергәндә спортка битарафлар алдында өстенлекләре булачак. "Чыгарылышлар өчен бу – бик зур стимул. Димәк, ГТОга да бердәм дәүләт имтиханнарына караган кебек җитди мөнәсәбәттә булачакбыз", – ди шәһәр мәктәпләренең берсендә укучы Ольга Логинова.

Аннан, илебез җитәкчелеге халыкның сәламәтлеген кайгыртуга алынган икән, димәк, гади кешеләр өчен дә кулай бассейннар, спорт клублары һәм секцияләр пәйда булыр дип ышанырга нигез бар. Һәм белгечләр әйтүенчә, ГТОны кайтару яшь буынны гына түгел, ә яшьлек чорлары спортны икенче планга калдырган буталчык үзгәртеп кору елларына туры килгән кешеләрне дә спортка җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

...Нурлатлыларның тестлаштыру рәвешендә тапшырган беренче нәтиҗәләре шул көннәрдә республиканың Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына җибәреләчәк. Ә мондый массакүләм ГТО нормалары тапшырулар алга таба даими үткәрелеп торачак, дип вәгъдә итә оештыручылар.

Илназ МӨБАРӘКШИН

ТЕЛӘСӘ НИНДИ КАТЛАУЛЫЛЫКТАГЫ ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР, ЖАЛЮЗИ
Профессиональ монтажлау.
Түбән бәяләр.8-937-527-43-15.

Аксубаевский инкубатор принимает заявки на бройлеры, гуси, утки, индюки.
8-927-671-64-51,
8(84344) 2-78-83.

«KRAUSS» ПЛАСТИК ТӘРӘЗӘЛӘРЕ
2015 елның 1 гыйнвареннан 31 декабренәчә
5 тәрәзәгә заказ биргәндә, 6нчысы бүләккә*
Авыл тәрәзәләре 2000 сум.
Откослар, тәрәзә тәпләре, москит челтәрләре.
Бөтен Татарстан буенча эшлибез.
%сыз бүлеп түләү (банклар катнашыннан башка).
*җентеклерәк 8-9274-000-606, 8-9272-449-000 тел. буенча.
«Свет-Окон» ОООсы.

Нурлатский филиал Акционерного общества Страховая компания «Чулпан»
информирует о заключении договоров обязательного страхования гражданской ответственности владельцев транспортных средств (ОСАГО) в соответствии с требованиями действующего законодательства и без требования заключения договоров страхования иного вида.
Нурлатский филиал АО СК «Чулпан» осуществляет страхование имущества граждан, сельскохозяйственных животных, средств наземного транспорта (КАСКО) и страхование от несчастных случаев граждан и детей,
Нурлатский филиал АО СК «Чулпан» находится по адресу:
РТ, г. Нурлат, ул. Советская, д. 193. Время работы в будние дни с 8:00 до 17:00.
Лиц. С №121616, выд. Федеральной службой страхового надзора 04.10.2006 г.
Реклама

Совет Нурлатского муниципального района
объявляет конкурс на замещение вакантной должности муниципальной службы ведущего специалиста Аппарата Совета Нурлатского муниципального района.
Для замещения должности муниципальной службы установлены следующие квалификационные требования:
к уровню профессионального образования: высшее образование (государственное и муниципальное управление, юридическое, педагогическое).
Для участия в конкурсе необходимы следующие документы: **документ об образовании, паспорт, трудовая книжка (копия), 2 фотографии, заключение медучреждения.**
Документы принимаются в течение 20 дней в отделе кадров по адресу: г.Нурлат, ул.Советская, 98, каб. №13.
Справки по телефону: 2-06-19.

НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ.
Низкие цены.
8-927-242-48-68.

КРУПНАЯ ДИСТРИБЬЮТЕРСКАЯ КОМПАНИЯ
приглашает на работу
ТОРГОВОГО ПРЕДСТАВИТЕЛЯ,
проживающего в г. Нурлат.
Опыт активных продаж, наличие личного а/м.
З/п от 35000, ГСМ, сот. связь, корпоративное обучение.
Тел. (846) 977-90-19, 8-960-811-09-92 г. Самара
Резюме на e-mail: suchkova@dalimo.ru

Европа сыйфатына ия
ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР
2015 елның 24 мартыннан 30 апреленә кадәр 4 түшәмгә заказ биргәндә, 5нчесе - бүләккә!
3 айга бүлеп түләү (банклар катнашыннан башка).
Җентеклерәк 8-937-776-32-46 т. буенча.
ИП Зигангиров А.А.

КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Үрнәк авылында туып, хәзерге вакытта **Нурлат шәһәрендә** яшәүче кадерлебез **Гөлназ Вәлимхәмәт кызы Абдуллинаны** юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз!

Котлы булсын туган көнең,
Күзләреңдә нурлар
сүнмәсен,
Бүгенгедәй шат елмайган
йөзең
Кайгы чаткылары
күрмәсен.
Дөньядагы һәрбер
яхшылыктан
Өлеш чыксын сиңа мул гына,
Без телибез сиңа ак бәхетләр,
Шатлыкларга илткән юл гына.

Иң изге теләкләр белән этиең Нәбиулла, әниең Тәнзилә, тормыш иптәшең Эдуард, улларың Эмиль, Гадел һәм Даутовлар гаиләсе.

Нурлатта яшәүче киленебез **Гөлназ Вәлимхәмәт кызы Абдуллинаны** юбилее белән ихлас күңелебездән тәбрик итәбез.

Котлы булсын,
Гөлназ, туган көнең,
Нурлар чәчсен
һәрчак йөзләрең,
Кайгы-хәсрәт
күрми, бәхет белән
Үтсен синең килер көннәрең.
Тормыш юлың
һәрчак балкып торсын,
Нурлы булсын синең күңелең,
Сәламәт бул,
ак бәхетләр белән
Гел шатлыкта
үтсен һәр көнең.

Иң изге теләкләр белән апаң Индира, җизнәң Хәлил, Рәфис, Эльмира, Эльвина, Айсылу.

НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом. Варианты. Т. 8-937-283-86-00.
*дом или обмен. Т. 8-919-684-40-03.
*кирпичный дом, надворные постройки. Т. 8-927-047-40-55.
*3-комнатная квартира, ул. Кариева,6. Т. 8-927-243-65-08.
*дом в с. Тюрнясево. Т. 8-927-435-12-10.
*новый дом без отделки, ул. Рябиновая. Т. 8-927-406-17-05.
*дом, с. Шламка. Т. 8-927-406-75-70.
*дом в д. Зузеево. Т. 8-919-687-02-79.
*комната, недорого или сдается. Т. 8-927-047-10-21.
*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек. Т. 8-927-671-58-18.
*3-комнатная квартира, ул. Нурлатская, 3 этаж, 60 кв.м, без ремонта, 1380000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, ул. Заводская, 1 этаж, 70 кв.м, 1 млн. руб., индивидуальное отопление. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, мансарда, ул. Ленинградская, 17, 78 кв.м, 850000. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Заводская, 1 этаж, 50 кв.м, 750000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Нефтяников, 3 этаж, 50 кв.м, ремонт, 1290000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 5 этаж, 60 кв.м, 1250000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом (кирпич), центр, 90 кв.м, баня, гараж, 2,5 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом (кирпич), ул. Курмышская, 90 кв.м, 1850000 руб., баня, гараж. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, мкр. Западный (Афганский), 120 кв.м, баня, гараж, 2,5 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*элитный коттедж, ул. Фахрутдинова, рядом ТЦ «Шифа», 6,7 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, д. Фомкино, 47 кв.м, 210000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*коттедж, ул. Космонавтов, баня, гараж, 3,8 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, с. Егоркино, 520000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, дер. Бурметьево, 700000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*коттедж, с. Тюрнясево, 2,8 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*нежилое помещение (магазин), д. Нижний Нурлат, 200 кв.м, 1 млн. руб., торг. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, новая, ул. Кариева, 2 этаж, 50 кв.м, лоджия, индивидуальное отопление, 1350000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*дом (ветхий), ж/д, 150000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*1-комнатная малосемейка, мкр. Яшлек, 550000 руб. Т.: 8-927-403-91-42, 8-927-245-66-78.
*дом в дер. Курманаево. Т. 8-937-616-45-84.
*гараж оформленный, мкр. Северный. Т. 8-927-242-09-56.
*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 9, 3 этаж. Т. 8-937-003-36-39.
*1-комнатная квартира, ул. Тимерзянова. Т. 8-937-284-02-92.
*дом, Чулпаново. Т. 8-927-249-00-75.
*2-комнатная квартира с мебелью, мкр. Яшлек, 3 этаж. Т. 8-927-435-98-23.
*дом, ул. Михеева. Т. 8-937-774-01-32.
*1-комнатная квартира, 32 кв.м, первый этаж, кухня 10 метров, балкон, с. Челно-Вершины. Т. 8-927-603-54-38.

АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-2115», 2007 г/в, пробег 110 тыс. км. Т. 8-937-52-55-909.
*«УАЗ Хантер», 2008 г/в, корейские мосты, коробка даймос, двигатель 409, недорого. Т. 8-960-035-69-29.
*„Лада приора", 2013 г.в., белого цвета. Т. 8-927-406-73-21.
*«КамАЗ-55111», самосвал, 1992 г/в. Т. 8-927-675-63-85.
*«КИА РИО», 2014 г/в. Т. 8-927-243-25-06.
*«УАЗ» бортовой на запчасти, культиватор, блок на «Т-25». Т. 8-927-672-00-92.

ДРУГОЕ

*куры-молодки. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.
*пшеница. Доставка. Т. 8-937-776-33-35.
*оптом огурцы свежие, тепличные, местные из Нурлатского района. Т. 8-927-679-54-19.
*пчелы. Т.: 2-17-06, 8-927-246-98-83.
*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-47-17.
*дрова. Т. 8-927-413-05-92.
*керамзит-керамблоки. Доставка. Т. 8-927-247-85-89.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*гусиные яйца («Линда»). Т. 8-927-460-75-68.
*свадебное платье (44-46 раз.), аксессуары в подарок. Т. 8-927-497-81-94.
*песок, ПГС. Т. 8-937-283-70-69.
*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-27-37.
*двигатель на классику, карбюратор. Т. 8-927-454-11-85.
*ООО «Спецэнергомонтаж» реализует керамзитобетонные блоки по приемлемым ценам. Обращаться: пер. Заводской, 1а (ЖБИ). Т.: 2-60-75, 2-50-90.
*стенка, дешево. Т. 2-73-89, после 18.00.
*спальный гарнитур, монитор, системный блок, б/у. Т. 8-927-443-07-45.
*диван угловой с креслом. Т. 8-927-247-07-22.
*бычки (молодняк) с доставкой. Т. 8-927-870-49-62.
*памперсы, размер №2, пеленки 90х60 см, инвалидная коляска (комнатная). Т. 8-927-404-75-92.
*сип кабель, кол. 120 м; брусчатка 500 шт.; 4-метровые фундаментные камни; вагон 2,50х6м. Т. 8-965-589-04-44.
*пчелосемьи. Т. 8-927-249-00-68.
*новый доильный аппарат. Т. 3-32-23.
*новая ванна, дешево. Т. 8-9270-35-72-68.
*коза. Т. 8-927-402-60-91.
*кровати 1,5-спальные (2 шт.), детская, шкаф книжный, комод, б/у, дешево. Т. 8-927-248-84-46.
*коляска-трансформер голубого цвета, недорого. Т. 8-927-248-84-46.
*корова. Т. 8-927-472-47-09.
*тележка для мотоблока, новая, цена 10000 руб. Т. 8-927-463-75-07.
*новый сруб бани (6х3,5). Т. 8-927-413-05-92.
*семена костер, люцерны. Т. 8-927-470-39-02.

РАЗНОЕ

*Йомшак жиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.
*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.
*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.
***Жалюзиның барлык төрләре, тиз. Т. 8-927-672-01-17.**
*Видеога, фотога төшерү. Т. 8-937-298-37-27 (Сергей).
*Тамада. Т. 8-927-416-18-07.
*чистим колодцы. Т. 8-939-393-37-24.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-419-56-48.
*натяжные потолки. Т. 8-927-036-53-65. (Алексей)
*копаем и чистим колодцы, вручную. Т.: 8-929-723-88-60, 8-986-711-25-30.
*помощь компьютеру. Т.8-909-308-22-56.
*копаем, чистим колодцы. Т. 8-927-481-51-72.
*домашний электрик. Т. 8-917-936-20-96.
*профессиональная сварка. Т. 8-987-278-51-77.
*кухни и шкафы-купе на заказ, недорого. Т. 8-927-241-26-41.
*ремонт холодильников. Т.: 8-937-610-58-78, 2-71-69.
*услуги погрузчика, "КамАЗа". Т. 8-927-404-92-21.
*г/п. Т. 8-927-401-11-76.
*ремонт ст.машин. Т.: 8-927-468-16-31, 8-917-926-34-78.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-247-93-50.
*Нурлат-Самара (из дома), 350 руб. Т. 8-927-673-79-46.
*АН «Город-Н». С нами продавать и покупать жилье легче! Т. 8-929-727-12-82, Ксения.
*обшиваем пластиком балконы, лоджии, дверные и оконные откосы, ванные, туалеты. Дешево, качественно, надежно. Т. 8-929-727-46-78.
*качественный ремонт квартир под ключ. Т. 8-937-773-98-04.
***кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.**
*«ГАЗель», грузоперевозки. Т. 8-927-486-10-22.
*ремонт компьютеров. Т. 8-927-474-71-20.

СДАЮТСЯ

*в аренду магазин 278,8 кв.м по ул. Советская, д. 183А (возле д/с «Сказка»). Обращаться по телефону: 8-917-251-93-15.
*квартира посуточно, командировочным. Т. 8-927-456-05-69.
*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.
*2-комнатная квартира, с/з. Т. 8-937-599-74-40.

ПОТЕРИ

*ключи от автомобиля с брелком утерянные около ТЦ «Шифа» прошу вернуть. Т. 8-927-41-99-784.
*утерянное удостоверение тракториста-машиниста, выданное на имя Минсабира Гумеровича Мустафина, считать недействительным.

ТРЕБУЕТСЯ

*парикмахер, маникюрист. Т. 8-927-421-80-33.
*водители на хлебовозку, лаборант. Т. 8-927-417-62-73.
*водитель, товаровед. Т. 2-32-99.
*инженер-сметчик. Т. 8-917-850-47-95.

КУПЛЮ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыймметкә. Т. 8-927-456-00-07.**
*КЫЙММӘТКӘ АВТО. Т. 8-937-588-36-46.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыймметкә. Т. 8-927-412-29-99.
*бетономешалку на 220V. Т. 8-937-297-83-77.
*3-комнатную квартиру в р-не ул. Ленинградская, мкр. 50 лет Победы, инд. отопление. Т. 8-9274-18-94-60.
*жилой кирпичный дом до 3 млн.руб. (с/з и мкр. афганский не предлагать). Т. 8-9274-18-94-60.
*лом, дорого. Т. 8-9274-222-666.
*КРС, лошадь. Т. 8-927-455-68-10.
*КРС. Т. 8-927-481-30-38.
*козу дойную зааненской породы. Т. 8-986-723-72-80.

ОБМЕН

*квартиру на дом с доплатой или куплю, ж/д, с/з, мкр. Западный (афганский) не предлагать. Т. 8-937-580-28-39.

СНИМУ

*семья чистую 2-комнатную квартиру в районе школы №9. Т. 8-937-773-98-04.
*1-комнатную квартиру, срочно. Т. 8-917-231-94-85.

ВНИМАНИЕ!!!
Скидки на все окна 30%
Компания " Оконные системы"


Окно 1300х1400
Поворотно-откидная створ
Подоконник 300 мм
Отлив 150мм
Монтаж с демонтажем
При заказе более 2-х око
- ПОДАРОК*

Rehau	KBE	Salamander	Novotex
7700руб	7200руб	6500руб	6000ру

т.8-927-742-66-67, 8-917-953-95-12
*Акция действует с 01.04.15 по 30.04.15 г. Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО «СВК». Рекл

РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ

Яңа Әлмәт авылында гом кичергән кадерле, сөекле, зиз әниебез, әбиебез **М негөл Хәбибулла кызы А еваны** соңгы юлга озатка хәлебезгә кереп, рухи һәм м ди яктан ярдәм иткән ба туганнарга, тирә-күршеләр дусларыбызга, авылдаш рыбызга зур рәхмәтебе белдерәбез. Гаиләләреге исәнлек, иминлек, тыныч телибез.

Рәхмәт белән ба лары, оныкла

ООО «Промочистка» предупреждает в связи с наступле ем паводкового пери водопроводную воду обходимо употребл только в кипяченном в

18 апреля
в поликлинике ЦРБ ведут пр специалисты МДЦ г.Казань по дующим направлениям:
эндокринология
неврология
кардиология
сосудистая хирургия (после 12
Врачи проведут исследовани высокотехнологичном оборуд нии.
Т. 8-917-269-54-27.
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАН НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.

В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ ПРАВЛЕНИЯМ:

18 апреля 2015 года
1. Гастроэнтерология.
2. Кардиология, ревматология.
3. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
4. Диетология.
5. Андрология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
6. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

19 апреля 2015 года
1. Отоларингология.
2. Эндокринология.
3. Взрослая, подростковая кардиология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование).

25 апреля 2015 года
1. Гастроэнтерология.
2. Онкогинекология-эндокринология, сп лизация по менопаузе.
3. Кардиология, ревматология.
4. Сосудистая хирургия, новый революц ный метод лечения варикозной болезни не требующего госпитализации и наркоз Лечение сосудистых звездочек.
5. Неврология.
6. Врачи проведут на высокотехнологич оборудовании исследование сердца, эхо диоскопию с ЦДК (цветное доплеровск картирование), исследования сосудов г ного мозга, верхних и нижних конечност

26 апреля 2015 года
1. Гинекология, репродуктология. Реше проблем при бесплодии. Ведение берем ности.
2. Врачи проведут исследования органо малого таза, плода на 1,2 и 3 триместра

КДЦ предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпа
Результаты обследования принимаются в БМСЭ.
Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.

Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста

Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru Реклама хезмәте телефоны: 8 (84345) 2-36-12

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы
"Татмедиа" АҖ филиалы
директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

Редакциянең адресы: 423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
Электрон адрес: e-mail: redak@list.ru
Телефоннар: 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия
Нәшер итүче: "ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маендa теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы "Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты: график буенча – 14.30, фактта – 14.30

татмедиа
Тираж - 1855

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама белдерүләренең тәгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Газета **чәршәмбе җомга** чыга.
Заказ №5936
Язылу индекс 16185
Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

© Язмаларны күчереп бастыру ред нең язмача рөхсәте белән генә мөм